| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 6 мая 2019 года пгт. Рыбная Слобода № 28

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, "Җирләү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пунктын, 12 статьясындагы 3 пунктын, “2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында” 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 3 пунктын үтәү максатыннан чыгып КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә (1, 2 нче кушымталар)

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 48А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендына Һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче М.В. Мәгыйзов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 6 маендагы 28 номерлы карарына 1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә
Хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1697 |
| 3. Мәрхүмнең тәнен (җәсәдләрен) зиратка (крематорийга) ташу | 929 |
| 4. Җирләү (кремацияләү һәм көлле урнаны бирү) | 3320,47 |
| Барлыгы: | 5946,47 |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 6 маендагы 28 номерлы карарына 2 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә хатыны(ире), якын туганнары, мәрхүмнең бүтән туганнарының яисә законлы вәкиле булмаганда яки җирләү мөмкин булмаган очракта, яки җирләүне үз өстенә алган башка зат тарафыннан җирләүне тормышка ашыруда

Бушлай күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне гыйбадәт киеме белән каплау | 468 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1229 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (мәетләрен) зиратка ташу | 929 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 3320,47 |
| Барлыгы | 5946,47 |